Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР№XXXV-2**

Балык Бистәсе штп. 2018елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыҗирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларыныңнорматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турындасудларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау хакында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 1, 4 өлешләренә, 15 маддәсенең 1 өлешенә, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсенең 2.1 пунктына ярашлы рәвештә Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау Тәртибен расларга (1 номерлы кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау буенча эшче төркем төзергә һәм аның составын расларга (2 номерлы кушымта).

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүнеТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары И.Г.Ибрагимовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль район
Башлыгы И.Р.Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның
16 октябрендәгеXXXV-2 номерлы
карарына кушымта №1

Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы
җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип,   карарларын һәм  гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы  мәсьәләләрен карау
Тәртибе

## I.Гомуми  нигезләмәләр

1.1.Әлеге ТәртипТатарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип,   карарларын һәм  гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы  мәсьәләләрен карау процедурасын тәгаенли (алга таба – Тәртип,хокук куллану практикасы мәсьәләләре), шулай ук Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип,   карарларын һәм  гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы  мәсьәләләрен карау буенча эшче төркемне төзү мәсьәләләрен, эшче төркем утырышларын уздыру  һәм андый  утырышлар йомгакларын рәсмиләштерү тәртибен җайга сала (алга таба – эшче төркем, хөкем карарлары).

## II. Эшче төркемне төзү һәм аның эшен оештыру тәртибе

2.1.Эшче төркем  аның рәисе, рәис урынбасары,  сәркатибе һәм  эшче төркем әгъзаларын  аныклап 7 кешедән ким булмаган сандагы составта оештырыла.  Эшче төркем составына Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарыныңкоррупциягә каршы һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен  җаваплы затлары кертелә.

Эшче төркем составы  Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районСоветы  карары белән раслана.

2.2.Эшче төркенең эше  хисап кварталыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр уздырылучы утырышларда хисап кварталында  хөкем карарлары турында мәгълүмат кергән очракта гамәлгә ашырыла.

Эшче төркем утырышына чакырылалар:

карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү өчен суд тарафыннан дөрес түгел дип танылган актның, карарның проектын әзерләүдә, гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районСоветы, Башкарма комитетының структура подразделениеләре, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы,Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре Советлары һәм Башкарма комитетлары хезмәткәрләре (алга таба – башка хезмәткәрләр);

акт, карар, гамәлләре (гамәл кылмавы) белән хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган затлар яки аларның вәкилләре (алга таба – башка затлар);

вәкил (вәкилләр):

җәмәгать оешмасының (оешмаларының) (җәмәгать оешмасы Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы тәкъдиме буенча тәгаенләнергә мөмкин);

район прокуратурасы.

Эшче төркем сәркатибе Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасына (Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы тәкъдиме буенча җәмәгать оешмасы вәкилләрен чакырган очракта) һәм вәкилләр кандидатуралары хакында район прокуратурасына запрослар җибәрә.

2.3.Хөкем карарлары турында мондый карарларның күчермәләре теркәлгән мәгълүмат Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аның составына керүче авыл җирлекләре тарафыннан эшче төркем рәисенә квартал саен тиешле карарлар хисап бирү кварталында чыгарылган очракта хисап кварталыннан соң килүче айның 5 числосыннан соңга калмыйча җибәрелә.

Мәгълүмат түбәндәгеләргә карата позицияне үз эченә алырга тиеш:

суд тарафыннан дөрес түгел (законсыз) дип танылганТатарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары (аның составына керүче авыл җирлекләре) һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актлар чыгаруына, карарлар кабул итүенә һәм гамәлләр кылуына (гамәл кылмавына) нигезләрне;

Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары (аның составына керүче авыл җирлекләре) һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затлары чыгарган норматив булмаган хокукый актларның дөрес түгел дип, карарларының һәм гамәлләренең (гамәл кылмавының) законсыз дип танылуларына нигезләрне;

башка хезмәткәрләрнең хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карауда катнашуын.

Карарларның күчермәләре теркәлгән чыгарылган хөкем карарлары турындагымәгълүмат белән бергә бер үк вакытта кылган гамәлләренең сәбәпләренә карата суд тарафыннан дөрес түгел (законсыз) дип танылган норматив булмаган хокукый актны, карарны кабул иткән яисә әзерләгән, гамәл кылган (гамәл кылмаган) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең)хезмәт урыныннан рәсми язуы(служебная записка) җибәрелә.

2.4. Эшче төркем рәисе хисап кварталыннан соң килүче айның 25 нче числосына кадәрге срокта эшче төркем утырышын үткәрү датасын һәм утырышка башка хезмәткәрләрне һәм бүтән затларны чакыруның зарурлыгын тәгаенли.

2.5.Эшче төркем сәркатибе эшче төркем утырышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында эшче төркем әгъзаларына, утырышка чакырылучы башка хезмәткәрләргә һәм бүтән затларга хәбәр итә.

Суд тарафыннан дөрес түгел (законсыз) дип танылган норматив булмаган хокукый актны чыгаруда катнашкан, гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) эшче төркем әгъзалары эшче төркем утырышына чакырылмыйлар.

2.6. Эшче төркем утырышы эшче төркем составының яртысыннан артыгы катнашканда вәкаләтле була. Утырыш эшче төркемнең рәисе тарафыннан үткәрелә, ул булмаганда – рәис урынбасары тарафыннан.

2.7.Эшче төркем хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау барышында:

хөкем карарларын анализлый, шул исәптән Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының чыгарган норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип, карарларының һәм гамәлләренең (гамәл кылмавының) законсыз дип танылуына нигезләрне;

ачыклый:

суд тарафыннан дөрес түгел (законсыз) дип танылган норматив булмаган хокукый актны чыгаруның, карар кабул итүнең һәм гамәлләр кылуның (гамәл кылмауның) сәбәпләрен һәм шартларын;

суд тарафыннан дөрес түгел (законсыз) дип танылган норматив булмаган хокукый актны, карар проектын әзерләүдә, шулай ук гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан затларның гамәлләрендә коррупция күренешләренең булу-булмавын, шул исәптән:

суд тарафыннан дөрес түгел дип танылган актны, карарны эшләүдә, шулай ук проектны килештергәндә һәм гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан затларның шәхси кызыксыну шартларының ( мәнфәгатьләр низагы вәзгыятенең);

андый затлар тарафыннан актны чыгаруда, карарны кабул итүдә, гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) кызыксынучы затларныңкоррупцион тыкшыну, бүтән төрле законсыз файдалану очраклары хакында хәбәр итмәве турында раслаучы хәлләрнең;

законнарга туры килмәгән хокукый актлар чыгаруны, шулай ук карарлар кабул итүне һәм гамәлләр кылуны (гамәл кылмауны) һәм коррупция күренешләрен кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар турында тәкъдимнәр эшли.

2.8.Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча эшче төркем коррупция күренешләре билгеләренең булу-булмавын раслаучы карар кабул итә, шулай ук законнарга каршы килә торган норматив булмаган хокукый актларны кабул итүне, гамәлләр кылуны (гамәл кылмауны) кисәтүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр эшли.

2.9. Әлеге Тәртипнең 2.7, 2.8 пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү нигезендә эшче төркемнең карары кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

2.10.Утырыш йомгаклары буенча сәркатип һәм утырышта рәислек итүченең

куллары куелган беркетмә төзелә. Беркетмәдә кабул ителгән карардан тыш күрсәтелә:

утырыш датасы, утырышны үткәрү вакыты һәм урыны;

утырышта катнашкан эшче төркем әгъзалары;

башка хезмәткәрләр;

утырышта чыгыш ясаучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм чыгышларның төп тезислары, әйтелгән тәкдимнәр;

тавыш бирү нәтиҗәләре;

кабул ителгән карар.

Беркетмәгә норматив булмаган актның суд тарафыннан дөрес түгел дип танылган хөкем карарларының күчермәләре, шулай ук эшче төркемнең карау предметы булып торган бүтән материаллар теркәлә.

Утырыш беркетмәсе, шулай ук суд тарафыннан дөрес түгел дип танылган норматив булмаган акт, хөкем карары Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында "Коррупциягә каршы тору" бүлегендә урнаштырылырга тиеш.

2.11. Эшче төркем рәисе утырыш узган көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча беркетмәне вазыйфалы затларына карата эшче төркем тарафыннан хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау нәтиҗәләре буенча рекомендацияләр бирелгән Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы (аның составына керүче авыл җирлеге) җитәкчесенә тиешле карарлар кабул итү өчен җибәрә.

2.12.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары (аның составына керүче авыл җирлеге) һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының карарларында һәм кылган гамәлләрендә (гамәл кылмавында) коррупцион тәшкил итүче булу ачыкланган очракта Эшче төркем рәисе беркетмәне һәм Эшче төркемнең карау предметы булып торган бүтән материалларны Татарстан Республикасы "Балык Бистәсе муниципаль районы"муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр низагын җайга салу һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урыны буенча тәртибенә таләпләрне үтәү буенча Комиссия каравына коррупцияне кисәтү һәм булдырмау буенча алга таба чаралар эшләү өчен җибәрә.

___________________________

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль район
Советының 2018 елның
16 октябрендәге XXXV-2
номерлыкарарына
кушымта №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
җирле үзидарә органнарының, аның составына керүче авыл җирлекләре һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларын дөрес түгел дип, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судлары карарларының канун көченә керү нәтиҗәләре буенча
хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау буенча
эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Ибрагимов<br>Илнур Галимович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары, эшче төркем рәисе |
| Исланов<br>Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыБашкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем рәисе урынбасары |
| Миндубаев<br>Илдар Илдусович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы урынбасары, эшче төркем сәркатибе |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Сафиуллина<br>НурияГабдрәшитовна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыБашкарма комитетының оештыру бүлеге (кадрлар буенча) башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында һәм Башкарма комитетында коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы зат |
| Җамалиев<br>Рөстәм Рәсимович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы |
| Әсләмов<br>Хәлил Гарәфиевич | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Әхмәтвәлиева | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе |

| | |
|---|---|
| Резедә Габделәхәтовна | муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составындагы җирлекләрнең җирле үзидарә органнарындакоррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы зат |
| Рәхимова<br>Эльвира Илмировна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасында коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы зат |
| Садыйков Айрат<br>Нәкыйфович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыФинанс-бюджет палатасы исәп һәм хисап бирү бүлегенең әйдәүче белгече, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыФинанс-бюджет палатасындакоррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы зат |